**Татарстан РеспубликасыЗәймуниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Югары Шепкә торак пунктында гражданнар җыены карары**

**15.11.2022** **№1**

«РоссияФедерациясендәҗирлеүзидарәоештыруныңгомумипринципларытурында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлыФедеральзаконның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасындаҗирлеүзидарәтурында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан РеспубликасыЗаконының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Югары Шепкә торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Югары Шепкә торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2023 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

-Яшьләр һәм Үзәк урамындагы балалар мәйданчыгын әйләндереп алу өчен койма сатып алу;

-урам утларын ремонтлау;

-урам исемнәре язылган элмә такталар сатып алу.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары Шепкә
авыл җирлеге башлыгы _______________ Камалиева Л.М.